КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 апрель г.Казань № 284

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эпидемияләргә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрдән файдалану тәртибе турында» 2010 ел, 3 декабрь, 989 нчы карары белән расланган Эпидемияләргә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрдән файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эпидемияләргә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрдән файдалану тәртибе турында» 2010 ел, 3 декабрь, 989 нчы карары белән расланган Эпидемияләргә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган субвенцияләрдән файдалану тәртибенә (Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының 2010 ел, 03 декабрь, 989 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктка «Барс.Web-Своды» хисапларны үзәкләштереп җыюның мәгълүмати-аналитик системасын кулланып, электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин